# ТУГАН ЯК КОШЛАРЫ



# ТУГАН ЯК КОШЛАРЫ

Әлеге электрон методик кулланма мәктәпкәчә яшьтәге балаларны туган як кошлары белән таныштыруны күздә тота. Һәр кош турында мәгълүмат эзләү күп вакытны ала, шуңа күрә бу кулланмада мөгаллимгә ярдәм йөзеннән республикабызда киң таралган күчмә һәм кышлаучы кошлар турында күптөрле мәгълүматлар бирелә. Кош турында, аның үзенчәлекләре, яшәү урыннары, туклануы, яшәү рәвеше турында гомуми белешмәләр елның төрле чорларында әзерлек этабында кирәк булачак. Кошлар турындагы мәгълүматлар мәктәп педагогына белем бирү процессын дөрес оештырырга ярдәм итәчәк.

Шуны да истә тотарга кирәк: кошлар турында төп белемнәрне һәм аларны карау-тәрбияләү турында мәгълүмат белән балалар шөгыльләр вакытында таныша. Әмма кошлар белән танышу процессын шөгыльләргә генә бәйләргә ярамый. Аларны көн дәвамында күзәтү теләген уяту зарур, чөнки күзәтү балаларның тереклекияләре белән кызыксынуын арттыра. Күзәтү цикллары балаларда күзәтүчәнлекне, табигать белән кызыксыну тойгысын үстерә, кошлар һәм аларның яшәү тирәлеге белән бәйләнеше турында белемнәр формалаштыра.

Якын-тирәдәге табигатькә чыгу балалар өчен файдалы һәм кызыклы. Өлкәннәр балалар белән бер анык максат куеп, бераз йөреп керә ала. Урамда йөреп кергән вакытны эчтәлекле танып-белү әңгәмәсе, педагогның аерым бер темага чыгышы, мультимедиа презентациясе белән тулыландырырга кирәк. Презентацияләр көндәлек тормышта күреп булмый торган ситуацияләрне (кош баласының йомыркадан чыгуы, кошларның куе ылыслы урманнарда тереклек итүе һ.б.) модельләштерергә юл ача. Мультимедиа презентацияләренең тагын бер өстенлеге - кошлар тавышын тыңлау. Кошлар тавышы яздырылган аудиофайллар куллану көндәлек тормышта ишетеп булмый торган кошларның тавышларын ишетергә мөмкинлек бирә.

Педагогның кош турында сөйләве балаларга материалны аңлаешлы формада җиткерү, күзәтелә торган объект турында анык күзаллаулар формалаштыру, балаларга билгеле булмаган яңа фактлар турында хәбәр итү чарасы булып тора. Әңгәмәдә иң мөһиме - баланы акрынлап яңа белемнәр алуга китерә торган сорауларның җентекләп уйланылган системасы.

Балалар әдәбияты педагогка сабыйларның аң-зиһенен баетырга, аларны әйләнә-тирә дөньяга тирәнтенрәк карый белә өйрәтергә, хис-кичерешләренә нәтиҗәлерәк тәэсир итәргә булышачак. Балаларга уку өчен китап сайлау мәсьәләсенә аерым таләпләр куела. Иң элек, «КУАНЫЧ» төбәк программасы тәкъдим иткән әдәбиятны кулланырга кирәк. Табигать белеме әдәбиятын барлык яшь төркемнәрендә куллану файдалы. Һәр яшь төркеме өчен дә уртак таләп – уку процессын турыдан-туры табигатьне күзәтү белән яраштырып алып бару. Шул чагында тышкы күзаллау мәгълүматны аңлау стадиясенә күчәчәк.

Табигать белән бәйле уңай хис-кичерешләрне үстерүдә дидактик һәм хәрәкәтчән уеннар ярдәм итә. Дидактик уеннарны ял вакытында, шөгыльләрдә һәм урамга чыккан вакытларда куллану максатка ярашлы. Лото, домино тибындагы уеннар, кискәләнгән һәм парлы рәсемнәр («Зоологик лото», «Ботаник лото», «Дүрт ел фасылы», «Домино» һ.б.) дәрестән буш вакытта куллану яхшырак. Балаларга мондый карточкалы өстәл уеннар ошый, чөнки аларда катнашу, алган белемнәренә таянып, җиңү яуларга мөмкинлек бирә.

Хәрәкәтчән уеннарны музыка белән бергә уздыру яхшырак. Алар кошларның гадәтләренә һәм яшәү рәвешенә охшарга тырышу белән бәйле. Бу уеннарны физкультура шөгыльләрендә яки саф һавага чыккан вакытта уйнау кулайрак.

Табигать белеменә карган китаплар уку, мультимедиа презентациясе белән танышу, күзәтү, уйнау балага кошлар турында эмоциональ тәэсирләр алырга, аларның төрле яшәү рәвешләре турында күзаллаулар булдырырга, кошларны карау-тәрбияләү турында мәгълүмат алырга юл ача.

Белем бирү эшчәнлеген оештырганда, мәктәпкәчә белем бирү оешмасы мөгаллиме кечкенәләр төркемендә балаларның кызыксынуын, өйрәнелә торган объектның ачык

билгеләрен һәм үзлекләрен карау, ишетү-тыңлау теләгенең даими дәрәҗәдә тоту кирәклеген исәпкә алырга тиеш. Уртанчылар төркемендә балаларның сабыйларча кызыксынучанлыгы, ә өлкән төркемдә – танып-белү омтылышы күзәтелә, баланың танып белү эшчәнлеге үсеш ала, шул ук вакытта ул фаразлар, эвристик фикерләр әйтергә өйрәнә. Белем бирү эшчәнлеге күзәтүнең концентрацияләнгән формасы буларак алып барылырга тиеш. Алдан планлаштырылган нәтиҗәгә проектлау технологиясен, проблеманы җентекләп тикшерү аша дидактик максатка ирешү ысулы буларак, аны туган як кошлары тавышларының аудиоязмаларын тыңлау, традицион булмаган методларны (экологик лабилизация, табигать объектларын сәнгати репрезентацияләү, экологик эмпатия, экологик идентификация, экологик кайгырту) куллану юлы белән аңлы рәвештә файдаланганда ирешеп була. Проектлау технологиясен куллану процессы уку-укыту методларын һәм чараларын берләштерергә, мәктәпкәчә белем бирүнең эчтәлеген структуралаштырырга, укыту процессына төзәтмәләр кертергә мөмкинлек бирә.

Иң кызыксынучан балалар өчен мәгълүмат, төсле фотосурәтләр, кош тавышларының аудиоязмалары, табышмаклар, әсәрләрендә кошларга мәдхия җырлаучы татар шагыйрьләренең шигырьләре белемнәрне гомумиләштерү этабында кирәк булачак.

Шул рәвешле, мәктәпкәчә белем бирүне тәмамлау этабында бала туган якның иң төп кошлары, аларның тышкы билгеләре, яшәү үзенчәлекләре, яшәү урыннары, туклану, төрле чорларда яшәү рәвеше турында белемнәргә ия булачак. Бала аңында дөньяның беренчел экологик картинасы барлыкка киләчәк, бу исә аның дөрес гамәлләр кылуына, ә алынган белемнәр аның табигый фәннәр өлкәсендә беренче сыйныф программасын үзләштерүенә ярдәм итәчәк.

Педагогка ярдәм йөзеннән кулланмада туган якның иң билгеле кышлаучы һәм күчмә кошлары турында мәгълүмат бирелде. Кошлар алфавит тәртибендә бирелгән.

## КЫШЛАУЧЫ КОШЛАР

### АЛА КАРГА (ВОРОНА)



Ала карга – хәйләкәр, җитез һәм тапкыр кош. Ул кеше белән янәшә яшәргә җайлашкан, аның гадәтләрен һәм холкын яхшы өйрәнгән, хәтта кеше эшчәнлегеннән үзенә файда алырга өйрәнгән.

Бу зур кош ачык төсе белән аерылып тормый. Карганың башы, томшыгы, бугазы, канатлары, койрыгы һәм аяклары кара, ә калган урыннары соры.

Яз җитү белән, күп кенә каргалар юлга җыена башлый. Алар шәһәрдән әрәмәлекләргә һәм урманнарга очып китәләр һәм анда агач башларында, куе куаклыкларда зур оя коралар, аларның эчке ягына мамык, коры үлән һәм каурыйлар җәяләр.

Зәңгәрсу һәм яшькелт төстәге, бөрчекле йомыркаларны ана кош утырып чыгара. Ә ата кош аны ашата. Ике атнадан соң йомыркадан бик комсыз кечкенә карга балалары чыга. Ата-аналар аларны тырышып ашата, ә аннары очарга һәм азык табарга өйрәтә

Ала каргалар каркылдап кына калмыйлар, алар, мәсәлән, эт өргән, кеше көлгән тавышны охшатып кычкыра беләләр, ә өйрәтелгән кошлар хәтта аерым сүзләр дә әйтәләр.

Ала каргалар этләрне үртәргә яраталар. Әйтик, эт оясыннан ерак түгел агачка кош утыра да: "һау! Һау! Һау!" – дип өргән тавыш чыгара. Эт котыра-котыра өрә башлый, ә карга шунна канәгать кала.

Күп кенә ала каргалар бик теләп күңел ача белә: кечкенә балалар кебек, боз тауларыннан, шома гөмбәзләрдән шуалар.

Ала каргаларны куркыту өчен, аларның куркыныч вакытта кычкырган тавышын яздыралар. Һәм шул язманы кушалар. Ала каргалар куркыныч сигналын ишетү белән очып китәләр.

***Мәкальләр***

Ала карга — азанчы , кара карга — казанчы.

Ала карга алдан кычкырып харап итә, калҗасын төлке алып китә.

Ала карга гына ата-анасына ошый.

Ала карга көз көне бер авыл җир очып бара икән дә, «ерак киттем бугай» дип, кире әйләнеп кайта, ди.

Ала каргада аласың булсын, курыкма.

Ала каргада аласың булсын, кыш кайтмаса, яз кайты**р.**

***Шигырьләр***

**Карга**

Барча кошның да үзенчә сайравы бар, шигъре бар.
Карга, мескен, җырлый белми, кычкыра тик: «кар» да «кар»!
*Габдулла Тукай*

**Ала карга коена**

...Агарды кара болыт,
Таралды күбек булып.
Якты кояш күренде,
Уйнап тамчыга кунды.

Шул вакыт ала карга,
Очып килде дә суга,
Арлы-бирле карады,
Мине дә күреп калды.

Кереп яңгыр суына,
Ала карга коена.
Су чәчрәтеп үзенә,
Шап-шап канатын суга.

Ә мин карыйм тын калып,
Таш булып торам катып.
Ала каргада күзем,
Бетеп калды шул сүзем.

Ә ул шап-шап юына,
Чумып йөзмәкче була.
Курыкмый ала карга,
Карга булганга әллә.

Озак кына коенды,
Яңгырның суы бетте.
Үләнгә чыкты карга,
Юеш канатын кага.

Үзен үзе селкетеп,
Калган суны саркытып.
Карга өстен киптерде,
Ояга очып китте.

Әллә күкәй салырга,
Әллә салган күкәйгә
Басырга утырырга,
Юынды ала карга.
*Лилия Ф. Гиматдинова-Хисамова*

**КҮГӘРЧЕН (ГОЛУБЬ)**



Кыска муенлы, тыгыз тәнле, урман һәм паркларда, чормаларда һәм аулак урыннарда парлап яши торган кош. Гадәттә, көтү-көтү булып тереклек итәләр. Полюслардан кала,күгәрченнәәрне бар җирдә дә очратырга мөмкин. Бик күп төрләре һәм бик күп төслеләре була.Безнең якларда иң киң таралганы – соргылт, күк яки ак төстәге күгәрчен.

Күгәрченнәр – кешеләргә беренчеләрдән булып ияләшкән кошлар. Юлны тиз табарга сәләтле күгәрченнәр, почта һәм телеграф булмаган заманнарда, хәбәр ташып, кешеләргә зур файда китергәннәр. Андыйларны «почта күгәрченләре» дип атыйлар. Ашыгыч хәбәрләрне тиз арада илтеп җиткереп, бигрәк тә сугыш вакытларында зур ярдәм иткәннәр. Бүгенге көндә дә төрле максатлардан берәр нинди мөһим язу, әйбер җибәрү өчен күгәрченнәрдән файдаланучылар бар.

Ата күгәрчен белән ана күгәрчен бер-берсенә бик игътибарлы, тугрыклыклы булганлыктан, аларның матур мөнәсәбәләре шигырьләрдә сөйләнә, җырларда җырлана. Бер-берсен кадерләп-хөрмәтләп яшәгән парларга да «күгәрченнәрдәй пар килгән», «күгәрченнәр кебек гөрләшеп яшиләр» диләр. Бик күп халыклар өчен күгәрченнәр – мәхәббәт, бәхет һәм тынычлык символы.

***Табышмаклар***

Гөрли-гөрли җырлый ул,
Кызыл читек кия ул.
Күлмәкләре күгелҗем,
Татулыкны сөя ул.

***Шигырьләр***

**Күгәрчен**
Бер кошка кызыгамын –
Тәпие кызыл аның.
Атлаган саен баш ия –
Гадәте кызык аның.
Гөлдер-гү, гөлдер-гү,
Бигрәк чибәр, кемдер бу?
Ак та була күгәрчен,
Күк тә була күгәрчен.
Уйный кояш нурларында –
Күктә була күгәрчен.
Гөлдер-гү, гөлдер-гү,
Бигрәк чибәр, кемдер бу?

Күк күгәрчен, күк була,
Төскә һава күк була.
Шуңа күрә, күрәсең,
Аның аты – күгәрчен.
Гөлдер-гү, гөлдер-гү,
Бигрәк җитез, өлгер бу.
Күгәрчен, гөрлә, гөрлә!
Өй түбәсендә – түрдә.
Күгәрчен тыныч көн күрә
Кешеләр белән бергә.
Гөлдер-гү, гөлдер-гү,
Гөрли торган көндер бу.
*Нури Арсланов*

**КЫЗЫЛТҮШ (ЗЯБЛИК)**



Кызылтүш күбесенчә урманда, паркларда яши торган киң таралган сайрар кош. Ата кош матурлыгы белән игътибарны җәлеп итә: түше һәм башының ян-яклары коңгырт-кызыл, башы күгелҗем-соры канатларында ачык беленеп торган ак сызыклар бар, ә ана кош гап-гади соргылт-көрән төстә. Яз көне ата кызылтүшләр – алданрак, ана кошлар соңрак кайта.

Сайрауларының өч өлештән торуына игътибар итәргә мөмкин. Ул 2-3 секунд дәвам итә дә тына, аннары яңадан башлана. Песнәк тавышына охшаган «пин-пин-пин» дигән авазлары шәрә агач башларыннан еракларга яңырый.

Кызылтүшләр ояларын агачка ясый һәм аны мүк, лишайниклар, агач кайрылары белән читтән бөтенләй күренмәслек итеп бик оста яшерәләр.

***Табышмаклар***

Башка кошлар арасыннан
Бик тиз танып аласың.
Башы – сары, түше – кызыл,
Сокланып таң каласың.

***Шигырьләр***

**Кызылтүшләр**
Кызылтүшләр чут-чут сайрый,
Яңгыратып урманны.
Шунда берсе күреп алды
Минем карап торганны.

«Без көньякка китәбез!» – дип
Юаналармы әллә?
Кызылтүшләр очып китте –
Оялалармы әллә?...

Белеп торам: оялдылар,
Хәтта мин дә оялам.
Кызыл түшләренә карап,
Моңаеп карап калдым.
*Ленар Шәех*

**ПЕСНӘК (СИНИЦА)**



Кара башлы, сары гәүдәле, конус формасындагы очлы томшыклы, озын койрыклы урман кошы. Ачык аерылып тора торган билгеләре буенча әлеге кошларны балалар бик җиңел таный. Чынлап та, киң кара галстук киеп куйган диярсең – сап-сары түше буйлап кара буй сызык төшә; битенә ай кунгандай, яңакларында томшык янынннан, күз асларыннан башланып, баш артына кадәр җиткән һәм муенга кадәр төшеп торгант ярымай формасындагы зур гына ап-ак таплары бар.

Песнәк агач куышларында, ояларда яши. Кайры ярыкларында кышлый торган бөҗәкләр белән туклана. Бер пар песнәк кыш буенда 40 төп җимеш агачын корткычлардан чистарта, миллионнарча бөҗәкләрне юк итә.

Песнәк кышын кеше яшәгән җиргә якынрак күченеп килә, җимлекләргә ярмалар белән сыйлана. Көнбагыш, кабак орлыгы, чикләвек, ит кисәген саеруча ярата. Җәй айларында көненә 500-600 зарарлы бөҗәк ашап, хуҗалыкларга зур файда китерә.

***Табышмаклар***

Яшькелт-сары төсле ул,
Бер кечкенә кошчык ул.

***Шигырьләр***

**Песнәк**
«Бигрәк суык кышларын,
Белмим, ничек кышлармын?
Азык табу бик кыен,
Җан асрау – бар уем», –
Яныма очып килде,
Бер песнәк шулай диде.
Ачыга икән бит песнәк,
Тик утырыйк без нишләп?!

Өйдәге бер тармадан
Әти җимлек ясады.
Тары, көнбагыш салдык,
Песнәк тәмләп ашады.
Сыйлансын әйдә песнәк,
Арыгандыр җәй эшләп.
Күп кортларны юк итте,
Җимлектә безнең рәхәт.
*Йолдыз Шәрапова*

**САЕСКАН (СОРОКА)**



Аклы-каралы каурыйлы, озын койрыклы, шаркылдау, шыкырдауга охшаган өзек-өзек тавышлар чыгара торган кош.

Саескан кешеләргә якынрак урыннарны сайлый. Бакчаларда, паркларда еш очрый. Керер өчен кечкенә генә тишек калдырып, агач башларына зур ботаклардан шар формасындагы оялар ясый. Җылырак булсын өчен, ояның тишеге көньякка каратып калдырыла. Бала чыгарганчы, саескан берничә оя ясап куярга мөмкин, соңыннан кайсы уңайлырак шунысына урнаша. Бу ерткыч кошларны алдау өчен дә әйбәт икән.

Төрле азыклар белән туклана, ашап бетермәгән өлешен җиргә күмеп яшереп куя һәм аны бик җайлы эзләп таба. Саескан башка кошларның ояларын туздырып, күкәйләрен алып зарар салырга да, бөҗәкләрне юк итеп, хуҗалыкларга файда китерергә дә мөмкин. Ул бик акыллы кошлардан санала. Шуның өстенә җитез, әрсез һәм кызыксынучан да әле: берәр нәрсә күрсә, тиз генә очып килеп тикшереп карый, ошаса күтәреп алып итә, аеруча ялтыравык әйберләргә кызыга.

***Табышмаклар***

Ак-карадан киенгән,
Бер минут та тик тормый.

***Шигырьләр***

**Саескан**

Шырык-шырык саескан,
Дөньяга хәбәр салган,
Имеш, карга, имансыз,
Нәни чебешне алган.
Ә үзе бу саескан
Саф түгел икән, баксаң,
Ялтыраган һәр әйберне
Оясына ташыган.

Тотыгыз, дип, каракны,
Карак кычкырыр башлап,
Алдан йөрер куркудан,
Куймасыннар, дип, фашлап.
Бар әле йөрүчеләр
Саескандай шыкырдап,
Гаеп табып юк-бардан,
Тиктомалга мыгырдап.
(Нур Ахунов)

**ТУКРАН (ДЯТЕЛ)**



Үткен озын томшыгы белән агачның кабыгын тишеп, үзагачтагы кортларны чүпләп туклана торган урман кошы. Тукран агач куышында оялый, каты томшыгы белән агачны уеп, үзенә куыш ясый. Җәен бөҗәкләр белән туенса, кышын күркәдәге орлыкларны да ашый.

Ул агач кәүсәсенә көчле тырнаклары белән ябышып, каты койрыгы белән терәлгән килеш, томшыгы белән тук-тук сугып, бөҗәкне эзләп таба да озын теле белән электереп ала. Тукранның теле башыннан да озынрак һәм ул кортларны җайлы гына кайрыдан тартып алырга мөмкинлек бирә. Көненә 900 гә кадәр бөҗәк ашап, корткычларны юкка чыгара торган тукранны «урман докторы» дип тә атыйлар.

Тукраннар җиргә төшми диярлек, аерым-аерым яшиләр. Тукылдаган тавышларыннан бер-берсен таныйлар, тирә-якта ят тукран тукылдый башласа, шунда ук сизеп алалар.

Зур чуар тукраннар бер секунд эчендә 20 тапкыр тукылдатып өлгерә. Алар моны шундый тиз эшлиләр ки, без хәтта аларның баш хәрәкәтләрен дә күзәтеп өлгерә алмас идек.

***Табышмаклар***

Агач башта тукылдык,
Тукый-тукый тук булдык.

***Шигырьләр***

**Тукран сые**
Тукран тукый – нарат чукый.
Тамак туйгач, тукып туктый.
Сиздерә бит инде сусын,
Ничек җайлар икән бусын?
Юк, җиргә дә төшмәде ул,
Кар суын да эчмәде ул.
Тукый-тукый каен тиште
Һәм ширбәтле суын эчте.
Каян белгән, каян күргән,
Өйрәнгән ул аны кемнән?
*Шәүкәт Галиев*

**Урман докторы**
Тукран һәр агачны
Тук-тук-тук сугып карый,
Көчле һәм очлы борыны
Шундый зур эшкә ярый.

Агач кимергән кортларны
Эзләп, чукып бетерә.
Урман докторы булып, ул
Бик күп файда китерә.
*Мәрзия Фәйзуллина*

**ҮРМӘЛӘЧ (ПОПОЛЗЕНЬ)**



Үрмәләч кошлар семьялыгыннан кыска койрыклы, туры һәм очлы озын томшыклы, агач буйлап бик яхшы үрмәли торган кечкенә кош. Урманда, паркларда яши. Ул кайры астындагы бөҗәкләр, орлык, чикләвек белән туклана.

Россиядә чыпчык зурлыгындагы кыска койрыклы төре – гади үрмәләч киң таралган. Гәүдәсенең өске өлеше, гадәттә, соры яки күксел, түше – ак. Яшәү тирәлегенә карап, түшләренең төсе башка төрле дә булырга мөмкин. Гади үрмәләчне бик җайлы танып була, ул маска кигән кебек: күзләре аша томшыгыннан алып башының артына кадәр кара сызык сузылган.

Туктамыйча, бер километрга кадәр юлны очып үтә ала. Сайрар кошлардан саналмаса да, тавышы бик көчле һәм матур, «тци-ит» кебек сыманрак үзенчәлекле сызгыруы бар, азык эзләгәндә, «тью-тью», «твит-твит» кебек авазлар чыгара.

Үрмәләч бик торыш һәм эшчән. Ул башка кошлардан запас җыя белүе белән аерылып тора. Салкын вакытларда ашар өчен, үзе яши торган агачның тишекләренә, ярыкларына, оя ролен үтәгән куышлыгына яисә аның аерым яшерен почмакларына алдан ук запас азык яшереп куя. Саклау урыны җитәрлек зур булган очракта, үрмәләчнең кышка дип җыйган запасы 1,5 кг кадәр җитәргә мөмкин.

***Табышмаклар***

Урманыбызда бер кош бар –
Кап-кара маска кигән
Кышкыга да запас җыйган –
Бигрәк тырыш икән.

**ЧЫПЧЫК (ВОРОБЕЙ)**




Күбесенчә урман-кырларда һәм авыл-шәһәрләрдә торак янында тереклек итә торган көрән-соры төстәге кечкенә кош.

Чыпчыклар төрле шартларда яшәргә җайлашкан. Оялары да төрле җирдә булырга мөмкин, гадәттә, өй кыегына, ташландык сыерчык оясына, агач куышына урнашалар. Ул безнең якларда бер җәй эчендә өч тапкыр бала чыгара. Һавада унбиш минуттан да озаграк оча алмый, аңа туктап ял итәргә, хәл алырга кирәк.

Бу әрсез, җитез кошлар җир шарының төрле почмакларына таралган. Көтү-көтү булып яшиләр, зарарлы бөҗәкләрне юк итеп файда китерәләр. Рәхмәт йөзеннән төрле илләрдә, шәһәрләрдә чыпчыкларга һәйкәлләр дә куелган. Аларның иң беренчесе – Американың Бостон шәһәрендәге һәйкәл. Юкка гына түгел, бакчаларга, хуҗалыкларга бик зур зыян салган зарарлы кортларны юк итеп, чыпчыклар Америка халкын ачлыктан коткарып калган.

***Табышмаклар***

Урмый, чәчми –
Ил өстендә көн итә.

**Шигырьләр**

**Чыпчык**
Тәрәз каршына
Килгән бер чыпчык.
Миңа кычкыра:
– Чык әле, – ди, – чык.

Алдый ул, беләм,
Гел шулай итә.
Йөгереп чыксам,
Оча да китә.
(Фәнис Яруллин)

**Чыпчыгым**
Бар минем
Кошчыгым –
Кечкенә чыпчыгым.
Беркөнне
Салкыннан
Җиргә ул егылган.
Ә аны
Мин күрдем,
Бүлмәгә
Китердем.
Терелткәч
Җылытып,
Уйнадым
Очыртып.
Мин аны
Яратам –
Иркәләп
Ашатам.
Ә тиздән
Кыш бетәр,
Чәчәкле
Яз җитәр.
Без тышка
Чыгарбыз,
Бергәләп
Уйнарбыз.
(Әнәс Кари)

**Тәрәзәне кем чиртә**
— Тәрәзәне кем чиртә:
Чык-чык! Чык-чык!
— Мин килдем шулай иртә,
— Чыпчык, чыпчык.
Бик тә ашыйсым килә.
Чик-чик! Чик-чик!
Йөгереп янына килдем,
Яраткан җимен бирдем.
— Үпкәләмә, дускаем,
Гафу ит, яме! — дидем.
(Резеда Вәлиева)

**ЯБАЛАК (СОВА**



Зур күзле, ыргаксыман томшыклы, кабарып торган йомшак каурыйлы, йомры башлы төнге ерткыч кош. Күз тирәсендәге йоннары диск сман аерылып тора. Ябалак ухылдаган, сызгырган, шаркылдап көлгән тавышлар чыгара. Бик әйбәт ишетә, төнлә тавышсыз очарга сәләтле.

Ябалак күзләре белән төрле якларга карый алмый, алдындагыны гына күрә. Тирә-ягын күрер өчен, аңа башын борып карарга туры килә. Әмма бу ябалакларга бернинди дә кыенлык тудырмый, чөнки муеннары бик хәрәкәтчән һәм башлары 270 градуска кадәр борыла ала. Тиз-тиз генә борылып, бөтен нәрсәне күзәтеп торалар, хәтта артларында нәрсә бар икәнен дә күрә алалар.

Ябалаклар үзләре оя кормый, кыяларга, агач куышларына яисә башка ерткыч кошларның ояларына урнашалар. Парлап яшиләр, бер сайлаган пары белән бик озак еллар, хәтта гомер буе бергә булырга мөмкиннәр.

***Табышмаклар***

Йә шаркылдап көлә икән,
Йә ухылдап куя ул.
Тычканнарга көн күрсәтми,
Бигрәк өлгер, чая шул!

***Шигырьләр***

**Ябалак**
Ябалак ауга чыга
Төн пәрдәсе ятуга.
Агач башына кача
Сызылып таң атуга.
(Ленар Шәех)

# КҮЧМӘ КОШЛАР

## АККОШ (ЛЕБЕДЬ)



Нәфис озын муенлы, төче сулыкларда парлы булып яши торган, казга охшаган зур кош. Аккош бик сизгер һәм сак кош, оясын да кеше керә алмаслык аулак урыннарда – камышлар арасында ясый. Коры җирдә йөрергә яратмый, күбесенче йөзеп хәрәкәт итә. Суда тавыш чыгармыйча йөзә ала.

Ана аккош, гадәттә, 4-8 йомырка сала һәм 35 көннән нәни аккошлар күренә башлый. Аккош бәбкәсе эти-әниләре кебек ак түгел, ә сары төстә була һәм аның мамык-каурыйлары ике елдан соң гына ак төскә керә. Аккош гаиләләре бик дус: үсеп җиткәннән соң да, бала кошлар әткә-әнкә аккош тирәсендә йөзеп йөрергә мөмкин.

Аккош Европадагы иң зур су кошы санала. Бик күп халыклар өчен матурлык, сафлык, горурлык, нәфислек символы булып тора. Гадәти тирәлектә 25-28 ел яшәргә мөмкин, әмма аккошларның саны кими бара, аларның күп төрләре Кызыл китапка кертелгән.

Билгеле булганча, аккошлар парлап яши һәм бер тапкыр сайлаган парына гомер буе тугры кала. Халык телендә бер-берсен сөйгән кешеләрне пар аккошларга тиңлиләр.

***Табышмаклар***

Күлләребезнең яме ул –
Нәфис кенә матур кош.
Исемдә «ак» сүзе бар,
Беләсезме бит, ул – ... *(аккош).*

***Шигырьләр***

**Язгы балкыш**

Язын күлләрдә
Искиткеч балкыш.
Җылы яклардан
Кайткан бит аккош.

Ул сайрамый да,
Тик йөзә бирә.
Шулчак күңелгә
Нәфислек керә.

Көчле булса да,
Мохтаҗ яклауга.
Их, аккошларны
Ничек сакларга?!

*Айдар Җамалиев*

**АКЧАРЛАК (ЧАЙКА)**



Озын канатлы һәм озын ыргаксыман томшыклы ак яки соры төстәге кош. Балык белән туклана, бик әйбәт йөзә. Маневрлар ясап озаклап очарга ярата.

Төрле сулыклар тирәсендә тереклек итүче акчарлаклар бөтен Җир шарында таралган. Алар теләсә кайда һәм теләсә нинди материалдан оя корырга мөмкин. Кайбер акчарлаклар диңгездән ерак урыннарда да оя кора ала. Оя ясар өчен, алар төркем-төркем булып җыелалар, гадәттә, меңәрләгән акчарлаклардан гыйбарәт зур колонияләр булып яшиләр.Ояларында 1–4 йомырка була. Ана акчарлак ата акчарлактан бераз кечкенәрәк булуы белән генә аерылып тора.

Акчарлакларның иң кечкенә төре саналган кечкенә акчарлакларның авырлыгы нибары 100-150 г, иң зуры булган диңгез акчарлакның авырлыгы 2 кг га кадәр җитәргә мөмкин. Акчарлаклар тозлы суны да эчә ала, чөнки күз өстендә урнашкан махсус бизләре аларның канын артык тоздан чистарта ала икән. Алар шактый кыю һәм әрсез кошлар, үз территорияләренә аяк басканда, кешеләргә дә һөҗүм итәргә мөмкиннәр.

***Табышмаклар***

Диңгез-күлләр тирәсендә
Очып йөри ул һаман.
Бертуктамый чаркылдый күк –
Тавышы бигрәк яман.

***Шигырьләр***

**Акчарлак**
Көймәбез артыннан бер кош
Ияреп очты, калмады.
Курыкмыйча якын килде,
Хәтта тотып алмады.

Бер дә бездән калмады,
Белмим, ничек армады.
Балыкны да оста тотты,
Булмаса да кармагы.

Озак озатып барды,
Канатын кагып алды.
Күрәсең,ул шулай безгә
Ак юллар теләп калды.

Ул үзе дә ап-ак бит,
Куйган кебек акшарлап.
Елгаларның яме ул
Ак теләкле акчарлак.
*Йолдыз Шәрапова*

**КАЗ (ГУСЬ)**



Озын муенлы, озын сары томшыклы, каңгылдаган тавыш чыгара, куркыту өчен ысылдый торган ак яки соры төстәге эре су кошы.

Каз әйбәт йөри, йөгерә, тиз оча, ә менә суга чуму, йөзү буенча үрдәк кебек үк оста түгел. Бу аңлашыла да, чөнки ул суда аккошка, үрдәккә караганда азрак була, күпчелек вакытын коры җирдә үткәрә. Үсемлекләр, үләннәр, орлыклар белән туклана.

Каз дигәч, күбебезнең күз алдына йорт казы килеп басадыр. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки каз – кешеләр тарафыннан кулга ияләштерелгән иң борынгы кошларның берсе. Каз мамыгыннан мендәрләр, ястык-түшәкләр ясыйлар. Элек, каләм булмаган чорда, каз каурые белән язганнар.

Кыр казлары күбрәк сазлыкларга, күлләргә якын җирләрдә тереклек итә. Алар җылы якка, зур төркемгә оешып, бик биектән очалар. Кайбер төркемдә хәтта меңгә якын каз булырга мөмкин. Каз якынча 25-30 ел яши.

***Табышмаклар***

Суда юынып алды,
Өстә коры калды.

**КАРА КАРГА (ГРАЧ)**



Кара карга кап-кара төстә була, ялтырап тора, бары зур томшыгы өстендә генә ак сызыгы бар. Элек барлык кара каргалар да көньякка очып киткәннәр. Хәзер аларның кайберләре безнең якларда, кешеләр янында кышлый.Ул оясын агач башында ясый һәм шунда бала чыгара.

Кара карга – иң файдалы кошларның берсе. Алар май коңгызларын, аларның личинкаларын, саранчаларны, кыр тычканнарын юк итәләр.

***Табышмаклар***

***Шигырьләр***

**Кара карга**
Аны яз кошы диләр,
Еракта кышлый диләр.
Беренче булып кайта да
Ул куа кышны диләр.
Кара карга кар куа, -
Кара җирләр калкуга,
Сабанчы белән бергә
Төшә дә җылы җиргә
Ул атлап йөри ипләп,
Төрле кортларны чүпләп.
Уйный кояш нурлары –
Ялтырый каурыйлары.
Кояш та кала күреп:
Кем оя салган үреп? –
Талда кара каргаларның
Йортлары бүрек-бүрек.
И матур шушы чаклар!
Бик кадерле кунаклар –
Каргалар кайтты диеп
Гөр килә ерганаклар.
*Нури Арсланов*

**Кара әфәнде**
Кап-кара ялтыравык каурый. –
Кыр тычканы, саранча,
Ул якынлашкач, калмый.
Томшыгында бар бер ак сызык,
Өп-өр-яңа френч кигән,
Атлап йөреше кызык.
«Әфенде» чакырганга, яз да ашыга.
Исемен кем дә белә,
Бу – кара карга!
*Айдар Җамалиев*

**КАРЛЫГАЧ (ЛАСТОЧКА)**



Аксыл түшле, икегә аерылып торган озын койрыклы, бик җитез оча торган кош. Карлыгачлар ояларын – өй кыекларында, кәрниз асларында, ә яр карлыгачлары биек текә ярларда ясый. Теләсә нинди корылмада гаҗәеп оя кора алуы белән ул башка кошлардан аерылып тора. Балчык ташып, аны селәгәе белән йомшартып һәм сылап, нык итеп ясаган оясына карлыгач берничә ел рәттән ояларга мөмкин.

Карлыгачлар күбесенчә һавада булалар, җиргә бик сирәк төшәләр, хәтта суны да очып барган килеш кенә эчеп алырга,балаларын да очып барган килеш ашатырга мөмкиннәр. «Карлыгачлар югары очса – көн яхшыра, түбән очса – начарлана» дигән сынамыш та бар. Чынлап та, яңгыр явар алдыннан бөҗәкләр түбәннәнрәк очканлыктан, көннәр буе бөҗәк аулау белән мәшгуль карлыгачларга да аскарак төшәргә туры килә.

Җәй буена бер карлыгач якынча миллион бөҗәк (чебен, черки, озынборын, күбәләк һ.б.) аулый ала. Язын алар иң соңгылардан булып, көннәр җылыта башлап, бөҗәкләр чыккач кына кайталар.

***Табышмаклар***

Кулы юк – балчык ташый,
Балтасы юк – өй ясый.

***Шигырьләр***

**Карлыгач**
Күптән инде түгел безнең тәрәзәгә капкачын
Оя итте минем сөйгән карлыгачым:
Ул көн буе авызы белән балчык ташый,
Балчык белән матур итеп оя ясый.
Күп эшләде иренмичә; бара-бара
Чыгарды ул матур-матур балалар да.
Ачыксалар карлыгачның балалары,
Чебен-черки тотып кайта аналары.
*Габдулла Тукай*

**КҮКЕ (КУКУШКА)**



Күке – урман кошы. Аны башка исем белән «кәккүк» дип тә йөртәләр. Урманда булган һәр кешенең күке күкелдәвен ишеткәне бар, мөгаен.

Күкеләрнең күбесе йомыркаларын башка кошларның ояларына сала. Бары йомыркаларның төсләре генә туры килсен. Күкенең карчыганыкы кебек сырлы күкрәген күрүгә, кошлар, куркып ояларыннан очып китәләр. Күкегә шул гына кирәк тә. Ул шул арада әлеге кошның оясына йомыркасын салып та куя. Аларның чит ояга елына 25 кә кадәр йомырка салулары билгеле.

***Табышмаклар***

Канаты бар, оясы юк,
Ят ояда баласы тук.

***Шигырьләр***

**Кәккүк**

Якты яз җиткәч,
Яшел урманнан
Кәккүк тавышы
Яңгырый һаман:
«Кәккүк! Кәккүк!
Кәккүк! Кәккүк!»
Башка кошлар күк,
Ул оя кормый,
Үстерми бала,
Җырлый да җырлый:
«Кәккүк! Кәккүк!
Кәккүк! Кәккүк!»
Ул чит ояга
Күкәйләр салган,
Эзли шуларны
Кычкырып һаман:
«Кәккүк! Кәккүк!
Кәккүк! Кәккүк!»
*Әхмәт Исхак*

**САНДУГАЧ (СОЛОВЕЙ)**



Коңгырт яки соргылт төстәге, чыпчыктан бераз гына зуррак булган кап-кара төймә күзле, озын койрыклы, нәфис тавышы күчмә сайрар кош.

Иң матур сайраучыларның берсе булса да, тышкы кыяфәте белән ул игътибарны җәлеп итми торган бик гади һәм гадәти кош. Аның турында «күренмәс кош» дип тә әйтәләр. Сандугачларны чынлап та күреп булмый диярлек, алар бик сак. Торак йортлардан ерак булмаган парк, бакчаларда тереклек итеп, җирдә яки куе куакларда оя корсалар да, ояларына саклык белән генә, кешеләргә күренмәслек итеп кенә төшә алар.

Сандугач Африкада кышлый, безнең якларга, иң соңгылардан булып, майда кайта. Аның сайравын да күбесенчә май айларында ишетергә мөмкин, чөнки бала чыгарган, үстергән вакытларда, ул җырлаудан туктап тора. Кешеләр кебек, сандугачлар да җырларга озак өйрәнә, өченче елында гына матур итеп сайрый башлый икән. Сайравын да ата сандугачлар гына сайрый. Аларның гаҗәеп җырларын аеруча төнлә, таң алдыннан тыңлап ләззәтләнергә мөмкин.

**Табышмаклар**

Ничек кенә карасаң
Күрә алмассың аны.
Колакларны назлый бары
Чут-чут итеп сайравы.

***Шигырьләр***

**Атказанган сандугач**
Ул сандугач – дус сандугач!
Көн дә бездә кунакта.
Минем өчен җырлар җырлый
Бакчабызда – куакта.

Сайрагач ул матур итеп,
Бик күңелле миңа да.
«Атказанган сандугач» дип
Исем бирдем мин аңа.

Аның ничек сайраганын
Тыңлатыр идем сезгә.
Сез үзегез дә ышаныр
Идегез минем сүзгә.

Ләкин җырчы сандугачым
Өйдә түгел – ул әле
Җылы якка гастрольләргә
Китеп барды шул әле!
*Роберт Миңнуллин*

**СЫЕРЧЫК (СКВОРЕЦ)**



Чыпчыксыманнар отрядыннан чем-кара ялтыравык каурыйлы, очлы канатлы, очлы туры томшыклыклы күчмә сайрар кош. Сыерчык – безнең иң яраткан, көтеп алган, кара каргалардан соң иртә язда әйләнеп кайта торган кунагыбыз. Алар агач куышларында, түбә асларында уентыларда, яр карлыгачы ояларында яшиләр, аеруча йорт тирәләрендәге кешеләр ясап элгән ояларны үз итәләр.

Сыерчык башка кошлар сайравын кабатлап та таң калдыра әле. Алар башкаруында карга, карлыгач, тургай кебек кошларның тавышларын да, бака бакылдаганын, песи мияулаганын да ишетергә мөмкин.

Басу һәм бакчаларны корткыч бөҗәкләрдән чистартып, бик зур файда китерә. Бер сыерчык гаиләсе бер көндә якынча 350 гә якын корткычны юк итә ала. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки сыерчыклар балаларына якынча һәр ике минут саен бөҗәк китереп тора икән.

**Табышмаклар**

Иртә язда килеп, безгә
Яз хәбәрен тарата.
Көне буе бөҗәк ташый –
Балаларын ярата.

***Шигырьләр***

**Сыерчык**
Шатлыгы сыймый эченә,
Сайрый ул сузып-сузып.
Йә әйләнә бытбылдыкка,
Йә җырлый тургай булып.

Бака булып та бакылдый,
Тартар да була ала.
Кызылтүш кебек тә сайрый,
Канатын кага-кага.

Юкка сөенми, аңа бит
Бик ошый яңа оя.
Шуны ясап биргән өчен,
Ул безгә концерт куя.
*Нәҗип Мадьяров*

**ТОРНА (ЖУРАВЛЬ)**



Озын муенлы һәм озын аяклы, торбадан чыккан кебек көчле тавышлы, матур гәүдәле саз кыш. Аның яңгыравык тавыш башка кошларныкыннан аерылып тора. Торна бик сак кош, берәр нинди куркыныч тойса, шунда ук кычкырып хәбәр бирә.

Безнең якларга кайткач, торна яңа оя ясамый, иске оясын эзләп табып, шуңа урнаша, 2-3 бала чыгара. Оя кору өчен судан бик ерак булмаган җирдә корырак урын сайлый. Җирне казып, чокыр кырыена ташлар, ботаклар тезә. Үсемле орлыклары, җиләк, балыклар белән туклана.

Торналарның ватаны – Төньяк Америка. Азия аша алар, Антарктида һәм Көньяк Америкадан кала, башка континентларга да таралганнар.

Торналар безне гаҗәп матур биюләре белән дә сокландыра әле. Аларның язгы бию-уеннарын ерактан күзәтеп торуы бик кызык: борылу, иелү, очып алу чиратлашкан синхрон хәрәкәтләр чынлап та искиткеч оста биюне хәтерләтә. Хәтта кешеләр дә биюне кабатларга, өйрәнергә омтыла. Япон, кытай, корея халыкларының торна биюен хәтерләткән борынгы биюләре дә бар.

***Табышмаклар***

Торрыйк-торрыйк торкылдашып,
Кайтып төштеләр безгә.
Канат кагып саубуллашып
Китәләр инде көзгә.

***Шигырьләр***

**Торналар килде**
Кар сулары аккан чакта,
Тезелешеп җылы яктан
Торналар кайтты безгә,
Канатлар какты безгә.

Кычкырдылар: «Торыйк-торыйк,
Сезнең белән дуслар булыйк,
Көзгә чаклы бергә торыйк!
«Торыйк-торыйк, торыйк-торыйк!»
*Гамил Афзал*

**ТУРГАЙ (ЖАВОРОНОК)**



Тургай – басу-кырларда, болынларда, көтүлекләрдә яши. Бер урында җилпенел тора ала торган, чыпчыктан бераз гына зуррак сайрар кош. Беренчеләрдән булып җылы якларга китә һәм барысыннан да алдарак март аенда ук кайта да. Тургайлар ачык урыннарда яши, ояларын җирдә кора.

Тургай – очканда сайрый торган сирәк кошларның берсе. Ул, сайраган килеш спираль буенча әйләнә-әйләнә, һаман югарырак күтәрелә, сайрап аска төшә, төшеп җиткәндә генә тынып кала, тагын өскә күтәрелә, тагын сайрый. Шулай ике-өч минуттан алып ун минутка кадәр туктаусыз сайрый ала. Тургайлар яхшы җырчылар гына түгел, менә дигән булышчыларыбыз да. Кырлардагы зарарлы бөҗәкләрне чүпләп тә, чүп үләннәренең орлыкларын ашап та, хуҗалыкка бик зур файда китерәләр.

***Табышмаклар***

Бер кошым бар: тынмый,
Агачка оя кормый;
Өе – җирдә,
Җыры – күктә.

***Шигырьләр***

**Тургай**
Ай-һай, тургай, биек менгәнсең,
Югарыдан безне күәмсең?
Без бит сине өзеләп сагындык,
Тавышыңнан бик тиз таныдык.
*Әминә Бикчәнтәева*

**Ятим тургай**
- Тургай, нигә моңлы син?
Нигә болай елыйсың?
- Инде елап ардым мин:
Япа-ялгыз калдым мин.
- Абау, шулай укмыни?
Балаларың юкмыни?
- Аждаһадай коточкыч
Мәрхәмәтсез бер очкын
Агу сипте басуга.
Балаларым барсы да
Шундук үлеп беттеләр...
Мине ятим иттеләр.
Әле безнең кадерне
Тора-бара белерсез.
Тургайларны бервакыт
Төштә генә күрерсез...
Белмим, нинди кеше сез?
Нишлисез?!
*Хәкимҗан Халиков*

**ЧЕЛӘН (ЦАПЛЯ)**



Зур туры томшыклы, озын нечкә муенлы, озын аяклы саз кошы. Аны елга-күлләрдә, сазлыкларда очратырга мөмкин. Челәнләр колонияләр булып яши. Антарктидадан кала барлык материкларда до очрый, җир-су хайваннары һәм сөйрәлүчеләр белән туклана.

Челән юкка гына суда бер аягында басып тормый: су салкын булганлыктан, башта бер аягын, аннары икенчесен җылыта. Бер аягында гына озак, сәгатләр буе басып торырга да мөмкин. Кыш көне, гадәттә, тозлы сулыкларда, җәй көне төче сулыкларда булуны кулай күрә. Миграция вакытында 2000 метр чамасы биеклеккә күтәрелеп, меңнәрчә километрларны очып үтә ала.

Оя кору кебек җаваплы эшне ана кошлар башкара, ә ата челәннәр аларга материал китереп тора. Шунысы кызык: ата челән белән ана челән тышкы яктан аерылмый диярлек.

***Табышмаклар***

Бер аягында гына
Басып тора ул гелән.
Сулыкларны бик ярата,
Исеме аның ... *(челән).*

**ЧӘҮКӘ (ГАЛКА)**



Чәүкә – шәһәр һәм авылларда очрый торган иң гадәти кош. Аларның күпчелеге кыш көне җылы якларга китми. Ояларын өй кыекларында, мич морҗаларында, манара башларында, агач куышларында ясый.

Ул каргадан кечкенәрәк, төтен сыман кара-көрән төстә, көлсу-көрән башлыклы була. Апрель башында дүрт-биш бала чыгара. Аларны бөҗәкләр һәм гусеницалар белән тукландыра. Көзгә кадәр чәүкәләр болыннарда, басуларда, көтүлекләрдә гаять күп бөҗәкләрне юк итәләр. Ә инде көзен, бөҗәкләр беткәч, бушаган иген басуларында орлык чүплиләр. Шәһәр җирендә яши торганнары, төрле калдыкларны ашап, «шәһәр санитарлары» вазифасын башкаралар.

***Табышмаклар***

Иләк күмер ил күчеп бара.(чәүкә көтүе)

***Шигырьләр***

**Файдалы чәүкәләр**

Апрельдә һәрчак
Тормыш җанлана
Тынлык югала:
Безнең чәүкәләр
Оялар кора,
Чыгара бала.

Бәләкәчләргә
Көл-көрән кошлар
Корт-бөҗәк ташый.
«Пи-пи-пи, рәхмәт!» –
Кошчыклар тәмләп,
Яратып ашый.

Чәүкәләр, үскәч,
Гаскәрләр булып,
Кырларны яулый:
Бөҗәкләр ашый.
Көзен басуда
Әрәмгә, тиккә
Бөртекләр калмый.

*Айдар Җамалиев*

**ШӘҮЛЕГӘН (ИВОЛГА)**



Гәүдәсенең озынлыгы якынча 25 см. Татарстанда иң җете төстәге кошларның берсе. Ата кошларның каурый капламы алтынсу-сары, канатлары, койрыгы һәм томшыгыннан күзенә таба үткән буй кара төстә. Ана һәм яшь кошлар саргылт-яшел, түшләрендә ак бөрчекләр бар. Күчмә кош. Татарстан территориясендә, гадәттә, май уртасында күренә башлыйлар. Оясын кәрзин рәвешендә кыяклы үсемлекләрнең сабагы һәм кыякларыннан, юкә кайрысыннан, киндер сүсеннән, туз һәм йоннан зур агачларның (имән, каен, нарат) ян ботаклары үсеп чыккан урыннарда, 2 дән 20 м га кадәрге биеклектә кора. 3–6 йомырка сала; ана кош утыра. Оялау чоры дәвамында ата кошлар туктаусыз сайрыйлар. Сайраулары — әкрен генә чәрелдәгән авазларга флейта тавышы килеп кушылуны хәтерләтә. Оядан чыккан балалар августка кадәр әнкә-әткә кошлар белән бергә була. Кышлау өчен сентябрьдә Африкага очып китәләр.

Корткычларны: май һәм июнь коңгызларын, бронзаклар, яфрактөргечләр, яфрагашарлар, филчекләр, төрле гусеницаларны юк итеп, урманнарга зур файда китерәләр. Җиләк һәм җимешләре белән тукланып, урман агач һәм куакларының таралуына булышалар.

**Викторина өчен сорау үрнәкләре**

1. Кайсы кош ауга төнлә чыга) *(ябалак)*
2. Нинди кошны «барабанчы» диләр? *(тукран)*
3. Безнең якларда яши торган иң күп ашаучы кошның берсе? *(песнәк)*
4. Кайсы кошның балалары әниләрен белми? *(күке)*
5. Нинди кош ялтыравык әйбергә кызыга? *(саескан)*
6. Кайсы кош җылы яктан иң беренче булып кайта? *(кара карга)*
7. Дөньяда сан ягыннан иң күп таралган кошлар? *(чыпчык)*